МИНИСТЕРСТВО ПРОМЫШЛЕННОСТИ И ТОРГОВЛИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СӘНӘГАТЬҺӘМ СӘҮДӘ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

20.04.2026 Казан ш. № 75-ОД

Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының «Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгында дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе турында» 2024 елның 16 июлендәге 146-ОД номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссияләре турында» 2010 елның 25 августындагы ПУ-569 номерлы Указы нигезендә,

б о е р ы к б и р ә м:

Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының «Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгында дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе турында» 2024 елның 16 июлендәге 146-ОД номерлы боерыгына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге боерык белән расланган Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе турында нигезләмәдә:

6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Комиссия Министрлык боерыгы белән төзелә. Әлеге боерык белән Комиссия составы һәм аның эш тәртибе раслана, Комиссия рәисе, аның урынбасары, секретаре билгеләп куела һәм Комиссиянең башка әгъзалары билгеләнә.

Комиссиянең барлык әгъзалары карарлар кабул иткәндә тигез хокукларга ия. Комиссия рәисе булмый торганда аның вазыйфаларын Комиссия рәисе урынбасары башкара.»;

7 пунктны түбәндәгечә үзгәртеп бирергә:

«7. Комиссия составына түбәндәгеләр керә:

«а) министр урынбасары (Комиссия рәисе), кадрлар бүлеге башлыгы (Комиссия рәисе урынбасары), кадрлар бүлегенең коррупциячел һәм башка хокук

бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи заты (Комиссия секретаре), Министрлыкның кадрлар бүлегенең, юридик бүлегенең, башка бүлекчәләренең министр тарафыннан билгеләнә торган дәүләт хезмәткәрләре;

б) Татарстан Республикасы Рәисенең Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсеннән һәм (яки) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының дәүләт хезмәте һәм кадрлар мәсьәләләре буенча бүлекчәсеннән вәкил;

в) эшчәнлекләре дәүләт хезмәтенә бәйле булган фәнни оешмалардан һәм һөнәри белем бирү оешмаларыннан, югары белем бирүче мәгариф оешмаларыннан һәм өстәмә һөнәри белем бирү оешмаларыннан вәкил (вәкилләр).»;

9 пунктында икенче җөмләне төшереп калдырырга;

15 пунктның «а» пунктчасының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«дәүләт хезмәткәрләре тарафыннан Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 30 декабрендәге ПУ-702 номерлы указы белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләр турында белешмәләр бирү хакындагы нигезләмәдә каралган белешмәләрне төгәл яисә тулы итеп тапшырмавы турында;»;

21 пунктның «а» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 30 декабрендәге ПУ-702 номерлы указы белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләр турында белешмәләр бирү хакындагы нигезләмәгә туры китереп, дәүләт граждан хезмәткәре тарафыннан тапшырылган белешмәләрнең төгәл һәм тулы булуын билгеләргә;»;

әлеге боерык белән расланган Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршлыгын җайга салу комиссиясе составында:

Комиссия составыннан чыгарырга: Ю.Ю. Кулагинны;

Комиссия составына кертергә:

Солтанова Диләрә Фаяз кызын – юридик бүлек җитәкчесен.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры урынбасары –
министр О.В. Коробченко